УДК 811.512.145

*Ялкын Янбаева-Әхмәтгалиева*

# «ХӘБӘРЧЕ» ЖУРНАЛЫ ТУРЫНДА

Статья посвящена обзору татарского журнала «Хәбәрче» («Вестник»). Это рукописный журнал на арабской графике, объёмом в 22 страницы, вышел в 1952 году в Стокгольме. Ему присвоили номер 1. Единственный номер журнала разошёлся в рукописных копиях, в Швеции в нескольких семьях видели этот журнал. Его создали татары, оказавшиеся в эмиграции. Журнал получился культурно-просветительский, татарско-общинный. Целью организаторов, которые выступают на страницах журнала как авторы статей, была попытка духовного объединения соплеменников с подобной им судьбой и сохранить родной язык в иноязычной среде. Статья знакомит читателя с некоторыми публикациями журнала «Хәбәрче», в подготовке к печати которых огромную роль сыграла Ялкын Янбаева-Ахметгалиева, деятельность которой анализируется в вводном слове доктора филологических наук И. Башировой.

**Ключевые слова:** газета «Хәбәрче», письменно-литературный язык, устный язык, арабская графика, латиница, кириллица, эмиграция , рукописные копии, татарская община, духовное объединение.

The article is devoted to the review of the Tatar magazine «Khuburche». This handwritten journal, in Arabic script, 22 pages plus 2 title pages, was published in Stockholm in 1952. It was numbered 1. The only issue of the magazine was distributed in handwritten copies; several families in Sweden saw this magazine. It was made by educated people with journalistic experience who ended up in emigration. The magazine turned out to be cultural and educational, for Tatar-community. The goal of the organizers, who appear on the pages of the magazine as authors of articles, was an attempt to spiritually unite fellow tribesmen with a similar fate and an attempt to preserve their native language in a foreign language environment. So they stated on the pages of their magazine. The article acquaints the reader with some of the publications of the magazine «Khuburche», in the publication of which Yalkyn Yanbaeva-Akhmutgalieva played a huge role, the activities of which are analyzed in the introductory word of Ph.D. n. I. Bashirova.

**Key words:** newspaper «Khuburche», written-literary language, oral language, Arabic graphics, Latin, Cyrillic, emigration, handwritten copies, Tatar community, spiritual association.

## Кереш сүз

Бердәнбер данә буларак дөнья күргән «Хәбәрче» журналы турындагы мәгълүматны безгә Израильдә яшәүче Ялкын Янбаева-Әхмәтгалиева җиткерде. Татар әдәби теле тарихы өлкәсендә фәнни тикшеренүләр алып баручы белгечләргә ул 1969 – 1989 елларда Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында эшләгән галимә буларак һәм урта гасырлар төрки-татар язма чыганагының телен өйрәнүгә багышланган «Исследование тюркоязычного памятника “Кисекбаш китабы”» исемле хезмәте (М.: Наука, 1979) буенча таныш.

Алга таба аның тарафыннан әлеге хезмәттә чагылыш тапкан тәртиптә «Әхвале Чингиз хан вә Аксак Тимер вә тәварихләрә махсус бәгъзе кыйсем-кыйтгалар» исемендәге дастан (Әхвәле Чингиз хан вә Аксак Тимер вә тавархлара махсус бәгъзе кыйсем-кыйтгалар. Казан: Импер. Ун-ты табыгханәсе, 1822) тикшерелә һәм «Коллекция исторических дастанов – памятник татарского литературного языка» дигән мәкаләсендә, «Дәфтәре-Чыңгыз-намә» исеме белән берләшә торган алты дастанның өйрәнелү тарихы күзаллана, аларның графика, орфография һәм морфология тармакларына караган хосусый үзенчәлекләре билгеләнә[1]. Дастанның лексик составы «Лексический материал хрестоматии Ибрагима Хальфина» дигән хезмәттә тикшерелә[2].

Ленинградта яшәү дәверендә Ялкын Янбаева-Әхмәтгалиева Россия Фәннәр академиясенең Көнчыгыш телләр институты филиалы китапханәсендә саклана торган иске татар китаплары коллекциясен барлый һәм 1802–1931 елларда чыккан 4 мең китапны системалаштыра. Нәтиҗәдә «Каталог старотатарских книг в Российской Академии наук» исемле хезмәт дөнья күрә (Jerusalem, 2010. 284 p.). Шушы вакытларда Ялкын ханым, балаларының соравы буенча, бабалары рухына багышлап, «Потомки Баязитова» дигән мемуарларын яза (Харьков: Торсинг, 2003. 64 с.; Казань: Иман, 1430/2009. 75 б.).

Иерусалимга күченгәч, галимә «Крымчакско-англо-русский словарь» төзеп бастыра. Хезмәтнең керешендә сүзлек өстендә эш барышы түбәндәгечә аңлатыла: «Хезмәт Ицхак Бен-Цви институтының Көнчыгыш яһүд җәмгыятьләрен (Иерусалим) өйрәнү буенча Академик совет кушуы белән башкарылган. Ул китапханәләрдә, архивларда һәм Иерусалимдагы шәхси коллекцияләрдә саклана торган материалларга нигезләнеп төзелгән. Кырымчак теле – Кырым татарлары сөйләшләренең берсе. Кырым ярымутравындагы җирле халыкның зур булмаган этник төркеме шушы телдә сөйләшкән, аның әгъзалары талмуд иудаизмын тотканнар. Алар, нигездә, ике телле булган: кырымчак (ягъни төрки) телендә аралашканнар, ә дини гыйбадәтләр һәм шәхси хат алышу иврит телендә алып барылган. ...Сүзлек дини һәм дөньяви характердагы стилистик яктан төрле чыганакларны үз эченә алган теге яки бу дәрәҗәдә тулы лексикон төзүдә беренче тәҗрибә булып тора. Сүзләрнең рус һәм инглиз телләренә тәрҗемәләре дә бирелгән»[3].

Шушы ук вакытларда «Песень Песней царя Соломона и Таргум на языке крымчаков» дигән хезмәт языла. Аның максаты түбәндәгечә билгеләнә: «Тәкъдим ителгән басма транскрипциясе кириллицада эшләнгән һәм рус теленә тәрҗемәсе бирелгән 1905 елда Петроковта басылып чыккан китаптан алынган «Җырларның җыры» поэмасы-

---

[1] Формирование татарского литературного языка, Казан, 1989, С. 65–82.

[2] Письменные памятники и проблемы культуры народов Востока. М., 1987. С. 3–7.

[3] Iala Ianbay. Krimchak Dictionary, Wiesbaden, 2016, Предисловие.

ның һәм Таргумның кырымчак телендәге текстларының беренче басмасы булып тора. Анда укучыга кырымчак диалектындагы (дөресрәге, этнолектындагы) әдәби җәүһәрнең рус теленә тулы кыйммәтле тәрҗемәсе тәкъдим ителә. Аны яһүдләр җәмгыятенең теләсә кайсы рус телле вәкиле алып укый ала. Кушымтада кырымчаклар тарихы турында кайбер мәгълүматлар һәм кырымчак диалектының кечкенә генә тасвирламасы урын алган. Шунысын ассызыклап әйтергә кирәк, бу басма кырымчакларга үз китапларын кире кайтарачак, шулай ук көнчыгыш яһүдләр мәдәниятен саклап калу эшендә зур ярдәм булачак...».

Алга таба хезмәтнең исемендәге төшенчә-терминнар аңлатыла: «Җырларның җыры» – иврит телендә лирик-интим һәм туй характерындагы яһүд җырлары җыентыгы. Әсәр яңа эраның II гасырында яһүдиләр Библиясе канунына (Танаха) 17 нче китап буларак кертелгән. Кануни яктан ул 117 шигырьдән тора һәм 8 бүлеккә бүленә (русча Библиядә – 6 бүлек). Традиция буенча «Җырларның җыры» патша Соломонга (ивритта аның тулы исеме ашер ле-шломо сүзләреннән тора, ягъни Соломонныкы) нисбәт ителә, әмма тикшеренүчеләр инде күптән әлеге фикерне кабул итмиләр һәм аны фольклор характерындагы җырлар җыентыгы дип саныйлар. Лексик һәм грамматик билгеләр буенча иң соңыннан язылган җырларның теле б. э. к. III гасырга карый... Кырымчак басмасында Таргум тәкъдим ителгән – ул Библия текстының киңәйтелгән аллегорик аңлатмасы, анда мәхәббәт лирикасы Израильнең изге тарихы тасвирламасына әверелә. Поэмага Таргум гарәпләр яулап алганнан соңгы чорда (VII–VIII гасырлар) язылган булса кирәк. Таргум термины библеистикада Библиянең төрле өлешләрен тәрҗемә итү өчен кулланыла...»[1]. Аңлашылганча, иврит телендә язылган текстның һәм аның кырымчак теленә тәрҗемәсенең Таргумы барлана, транскрипцияләнә, беренче мәртәбә рус теленә тәрҗемә ителә, сүз башы языла, кушымтасы (факсимиле) бирелә. Шулай ук тикшерелә торган текстның өйрәнелү дәрәҗәсе, тәрҗемәләре, авторлар тарафыннан ни рәвешле файдаланылуы күзәтелә. Хәзерге татар теленә мөнәсәбәттә караганда, татар әдәби теле һәм диалектлары белән чагыштырып күзәтү максатыннан, кырымчак телендәге варианты мөһим санала.

Гарәп графикасындагы «Хәбәрче» журналын тикшерүгә багышланган мәкаләсендә Ялкын Янбаева Скандинавия төбәгендәге татар диаспорасы турында мәгълүмат бирә, текстны транскрипцияли, үзенең алдагы хезмәтләрендә чагылыш тапкан язма чыганакларның телен тикшерү тәртибендә бу журнал теленә дә анализ ясый. Авторның стилен саклау максатыннан, текст, асылда, үзгәртелмичә бирелә. Татар халкы өчен гадәти, яхшы таныш булган мәгълүматларны үз эченә алган кайбер астөшермәләрне кыскарту, аерым искәрмәләрне өстәү, билгеле бер дәрәҗәдә, хәзерге татар язма әдәби теле нормасын саклау

[1] Янбай, 2017, с. 5–10.

максаты күздә тотылып, газетаның транскрипциясен редакцияләү безнең тарафтан башкарылды.

**Йомгаклау сүзе.** XX гасырның 50 нче елларында язмыш кушуы буенча чит илләрдә яшәргә мәҗбүр булган өч-дүрт татар зыялысы, үҗәтлек күрсәтеп, язма әдәбият туплап, журнал чыгару эшенә керешә. Нәтиҗәдә халкыбызның тарихи нигезе, дине, теле, җырлары, мәзәкләре турында мәгълүмат бирелә торган текстлар туплана. Ни хикмәт, татар кешесе җир шарының кайсы гына почмагында яшәргә мәҗбүр ителсә дә, иң беренче эше итеп, кулына каләм ала, халкының дине, ана теле турындагы уй-фикерләрен, берләшеп яшәү теләген милләттәшләренә җиткерергә тырыша. Башларына төшкән сәяси хәлләрдән туйган бу шәхесләр сәясәт турында язмаска өндиләр. Әмма әлеге язмаларны уку барышында халкыбызның башыннан кичкән сәяси-иҗтимагый тормыш күз алдына килеп баса.

*И.Б. Бәширова*

## Татар диаспорасы турында

Скандинавиядә, аерым алганда, Швециядә һәм Финляндиядә татарлар шактый күп яши: мөселман сөнниләр дә, ортодоксаль христианнар – керәшеннәр дә. Аларның төгәл саннары билгеле түгел, чөнки Швециядә, мәсәлән, бер генә анкетада да милләт графасы юк. Дөрес, тарихчыларга, Явыз Иван чорыннан башлап (бәлки тагын да иртәрәк), татарларның Россиядән бирегә берничә дулкын булып күченеп килүләре билгеле. Зур дулкын 1897 елда Стокгольмдагы сәнәгать күргәзмәсеннән соң теркәлә. Яңа эмигрантларның күбесе Швециядә өйләнешәләр, шулай ук күпләр Россиядән үз туганнарын һәм күршеләрен алып киләләр. Алар барысы да мондагы тормышка, үз диннәрен саклаган хәлдә, уңышлы кереп китәләр, әмма аларның дәфен кылынуы гына Финляндиядә була [Svanberg, s. 143 – 158]. 1949 елда, ниһаять, Стокгольмда Төрки-мөселман мәдәни җәмгыяте оештырыла, аның химаясе астында 1952 елда «Хәбәрче» журналының беренче саны дөнья күрә. Аны журналистлык тәҗрибәсенә ия белемле (әмма эмиграциягә киткән) кешеләр чыгара[1]. Шул ук вакытта Стокгольмда мөселман зираты да ачыла, бу турыда безнең журналдагы «Язмыш» повестенда искә алына.

Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк, журнал 1952 елның декабрендә чыга, 2 айдан Сталин вафат була, әмма аның турында да, Ленин турында да бернинди хәбәр юк. Дөньяның Бөек затларыннан

[1] Мәсәлән, күренекле галим Дәүләтшин Тимербәк Динмөхәммәт улы (1904–1983), тарихчы, юрист,җәмәгать эшлеклесе [Татар энциклопедиясе, 1999, с. 165]; Хәмидулла Хәсән (1895–1988), язучы, 11 шигырь, пьеса, хикәя, повестьлар җыентыгы, «Мөһаҗир бәхете» романы авторы [Татар энциклопедиясе, 1999, с. 626].

бары Кәмал Ататөрк кенә сайлап алына (1938 елда вафат), аңа бер шигырь багышлана – 13 (10) биттә[1].

Әдәби сүз татар мохитендә һәрвакыт популяр булды. Урта гасырлардан башлап халыкның мәдәни тормышында аңа ихтыяҗның зур булуы популяр әдәби әсәрләрнең күпсанлы кулъязмалары белән дәлилләнә [Фәсиев, б. 7–44]. 200 ел элек кулъязмаларга алмашка килгән басма продукциягә, китаплар, газета-журналлар булсынмы, укучылар арасында сорау зур була. Немец галиме Гетчның 1913 елда чыккан китабында, Идел буе татарларының ни рәвешле белем алулары турында языла: «...1910 елда аларның меңнән артык басма китабы, йөздән артык язучысы, 6 югары, 5 мең түбән мәктәбе була. Казан татарларында 150 кешегә бер мәчет, бер мулла булса, шундагы ук русларда һәм башка христиан халыкларында 1500 кешегә бер священник туры килә. Татарларда 100 ир һәм кыз балага – бер мәктәп, христианнарда исә 1500–3000 кешегә – бер мәктәп. Китап һәм газеталар тарату буенча мөселман татарлар христианнардан тагын да алга киткәннәр. В.И. Ленин да үз вакытында бу саннарга игътибар итә һәм, аларны күчереп алып, татарның панисламизм таратуыннан сак булырга чакыра» [Татар грамматикасы, 1998, б. 50–51].

Шулай итеп, исәп-хисап дөрес булып, планнар тормышка ашырылырга тиеш иде …

## Журнал теленең графо-орфографик һәм морфологик үзенчәлекләре

Журналның бу саны тулысынча гарәп хәрефләрендә бер кеше кулы белән язылган. Гарәп-фарсы алынмалары, төрки-татар язма теленең күп гасырлык традициясен дәвам итеп, күптәнге үз теле кагыйдәләре буенча кулланыла. Журнал текстында алынма фарсы сүзләре *дуст* һәм *шад, -лык* төрки кушымчасы кушылганда, тамырдагы ахыргы тартыклар үзгәрешсез кала: *дустлык* (8, б), *шадлык* (8, б). Хәзерге татар телендә – *дуслык, шатлык*. Журналда гарәптән кергән кайбер сүзләр хәзерге татар телендә рус алынмалары белән алыштырылган, мәсәлән, тәрәккый «прогресс» (4, а) һ.б.

Төрки-татар сүзләре татар теле фонетикасына якынайтылган Яңа имля буенча языла, анда тартыклар өчен «артык» гарәп хәрефләре төшереп калдырыла, татар сузыклары өчен тамгалар өстәлә. Бу орфографияне 1920 елгы реформадан соң кабул итәләр. Ул нибары 1927 елга кадәр, СССР тюркологларының Казанда узган өченче конференциясендә латин графикасы нигезендәге алфавит кабул ителгәнче генә яши [Курбатов, б. 58, 85]. «Хәбәрче» журналы редакциясе әгъзалары да бу яңа алфавит белән таныш булганнар, өч урында латин орфографиясе кулланылган: беренче титул битеннән тыш, 23 (20) биттә һәм 18 (15) битнең сул яртысында. Әмма бу – яңа

[1] Монда һәм алга таба җәяләр эчендә цифрлар белән бит саны, хәреф белән багана бирелә.

орфография («Яңалиф») түгел, ә төрек графикасыннан алынган латин хәрефләре. 23–20 бит тулысынча латин хәрефләре белән башкарылган, шуннан язучының төрек графикасын татар теленә җайлаштырырга омтылуы күренә. Төзүче борын тартыгы өчен *й* тамгасын өсти; ул бары тик татар сүзләреннән генә файдалана, әмма татар сүзе *эт*не төрекнең *ит*е белән бутый, татарча *бер* урынына *бир* дип яза, түбән күтәрелешле иренләшмәгән *ә* сузыгына тамга таба алмый һәм аны *е* белән алмаштыра, бу исә татар фонетикасына туры килми. Бу биттәге башваткычның биреме – «төрек алфавитының беренче хәрефе», һәм, күрәсең, укучылар аның җавабын белә.

Күптән түгел чыккан халык җырлары җыентыгына рецензиянең 22 (19) битендә аның «Казан латин хәрефләре» белән язылганлыгы искәртелгән. Билгеле булганча, 1939 елда Советлар Союзының бөтен төрки телле халыклары орфографиясе кирилл графикасына күчерелә [Курбатов, б. 58, 85] һәм ул бүгенге көндә дә гамәлдә.

Журнал телендә без *торганлар* «(5, а), *сатканлар* (4, б), *салыб биргәнләр* (алар өчен) «(5, а), *үләнләр* (3, а) кебек язылышны очратабыз, татар әдәби телендә: *торганнар, сатканнар, салып биргәннәр* һ.б. Чөнки күплек саны кушымчасы *-лар/-ләр* кушылганда, тамырдагы *м, н, ң* борын тартыкларының прогрессив ассимиляциясе күзәтелә. Бу күренешне белгечләр шул заманда ук теркәп куйганнар (8).

Чыгыш килеш кушымчасының яңгырау варианты ялганганда, тамырдагы соңгы саңгырау тартыкны сакларга омтылу күзәтелә, мәсәлән, *ташдан* (5, а), *бер якдан* (4, а), *көмешдән* (4, а), *балчыкдан* (5, а) һ.б.

III зат берлектә һәм күплектә үткән заман аффиксының еш кына хәтта саңгырау тартыклардан соң да яңгырау варианты *-ды*/*-де* кушыла, мәсәлән, *чыкды* (7, а), *тәбрикләшде* (8, а), *күрсәтделәр* (8, а).

Урын килешендә яңгырау вариант кына кулланылмый, мәсәлән, *вакытда* (5, а), *бәйләнешдә* (3, а), әмма *тарихта* (3, а).

Хәл фигыльләрдә хәзерге вакыттагы *-ып/-ип* урынына журнал телендә традицион рәвештә ахырда яңгырау *б* тартыгы языла: *булеб* (3, а), *чыгыб* (3, а), һәм ни өчендер, мөгаен аналогия буенча, *күб* (4, а һ.б.). Берничә тапкыр очраган *углы* сүзенең төрле формаларында да традицион язылыш күзәтелә. Журналда хәзерге *белән* бәйлеге белән беррәттән борынгы *илән* формасы да (7, а һ.б.) кулланыла.

Текст синонимнарга бай, бер мисалга тукталыйк. *Гүзәл, матур, ямьле* сүзләре матур мәгънәсендә кулланыла. Хәзерге татар әдәби телендә *чибәр* сүзе дә шул ук мәгънәдә.

Алынма һәм рус теле аша кергән сүзләрнең орфографиясе аларның татарча әйтелешенә туры килә, мәсәлән, *чиркәү* «церковь» (4, б), *афтамабиль* «автомобиль» (7, а, б), *гәзитә* «газета» (7, б), *нигр* «негр» (7, а) һ.б. Хәзерге татар телендә рус алынмалары рус теле орфографиясе кагыйдәләре буенча языла. Шул ук вакытта кайбер график очракларда ике телдә дә әлеге сүзләрнең әйтелешендәге аерманы билгеләү мөмкин түгел, мәсәлән, *техника* (6,а), *район* (4,б), *зал*

(8, а) һ.б. Швеция башкаласы атамасының (*Истукхульм* / Стокгольм) төрки фонетика кагыйдәләре нигезендә язылышы кызыклы: алынма сүзләрдә сүз башында ике тартык янәшә килгәндә, бигрәк тә өрелмәле һәм йомык тартыклар булганда, протеза рәвешендәге сузык аваз пәйда була, мәсәлән, Истанбул < Стамбул. Тексттан тагын бер мисал: *Эспас районы* / Спас районы (4, б) .

*Яурупа* / Европа (3, а) сүзенең графикасы журнал телендә иренирен [в] авазы белән күрсәтелә, соңрак ул ирен-теш авазына алыштырыла.

Шул рәвешле, журналның теле турында шуны әйтергә мөмкин: ул, гарәп-фарсы алынмаларының график-орфографик нормаларын, төрки-татар һәм рус алынмалары вариативлыгының орфографик үзенчәлекләрен саклап, традицион әдәби тел белән язылган. Төрек графикасыннан алынган латин хәрефләренең кулланылуы шул замандагы телнең хәл-халәтен чагылдыра дип саный алабыз.

**Әдәбият**

Svanberg, I. & Westerlund, D. (eds.). Muslim Tatar Minorities in the Baltic Sea Region. Brill, 2016.

*Кол Гали.* Кыйссаи Йосыф (Йосыф турында кыйсса) / төп текстны әзерләүче, кереш мәкаләне, искәрмә һәм аңлатмаларны, кулъязмаларның тасвирламасын язучы Фазыл Фасиев. Казан, Татар. кит. нәшр., 1983.

Татар грамматикасы. Т. 1. М.: Инсан; Казан: Фикер, 1998.

*Вәлиди Җ.* Татар теленең грамматикасы, 1919 // Сайланма хезмәтләр. Казан: Мәгариф, 2007. Б. 55.

*Курбатов Х.Р.* Татар әдәби теленең алфавит һәм орфография тарихы. Казан: Татар. кит. нәшр.,1999. Б. 58, 85.

*Хангилдин В.Н.* Татар теле грамматикасы (морфология буенча очерклар). Казан, 1954. С. 61.

*Poppe N.* Tatar Manual. Descriptive Grammar and Texts with a Tatar-English Glossary. Bloomington. The Hagae. 1963.

## «ХӘБӘРЧЕ» ЖУРНАЛЫ СӘХИФӘЛӘРЕ

(б. 1) Heberci. isvicdegi dini-medeni-türk-islam oyusmasi karsinda vakitli reviste cigariladir No 1, dek. – 1952 – STOCKHOLM

(б. 2 – 1) Бу санда:

1. Теләк – Хәбәрче идарәсе
2. Болгар ханлыгы – Т. Дәүләтшин
3. Язмыш – Абу Бәкир
4. Төрек углы – Х. Хәмидулла
5. Ата төрек. Әнкәй (шигырьләр) Минһаҗ
6. Байрак тартышы – Х. Хәмидулла
7. Изге Мәккә шәһәре электрлаштырыла
8. И. Гомәркәйгә 75 яшь
9. Беләсезме?
10. Яңа Хуҗа

11. Почта көтәсе – килгән хатлар
12. Халкыбызның җырлары
13. Буш вакытта – башваткычлар

(б. 3–2) Хәбәрче. Ишвичдәге дини-мәдәни-төрк-ислам оешмасы каршында вакытлы рәвешдә чыгарыладыр. Беренче сан.

Декабрь – 52 нче сәнә – Истукхульм шәһәре. Адрес: «Hebercі» Box 82 Upplands, vasby (Sweden).

(б. 4 – 3а) **Теләк**

Истукхульм шәһәрендәге дини-мәдәни-төрек-ислам оешмасы каршында вакытлы рәвештә чыгарыла торган «Хәбәрче» мәҗмугасы үзенең каршына түбәндәге бурычларны куя: 1. «Хәбәрче»нең тоткан юлы [*лакуна*] ки милләттәшләрен бигрәк тә әгъзаларны оешманың эшләре белән якындан таныштырыб тору. Башка илләрдәге мөселман оешмаларының эшләренә дә хәбәрләр биреб тору.

2. Чит илләрдәге милләттәшләр белән дини-мәдәни-милли иптәшләре булган [*лакуна*] һәм файдалы фикерләр алмашу вә тәкъдим тәрбия, тарихи әдәбият – яшьләргә, хатын-кызларга һәм балаларга [*лакуна*] теләкләрен җыя алган мәҗмуганы биреб [*лакуна*], халкыбыз өчен файдалы фикерләрен ачу.

(б. 4 – 3б) Бу башланган эштә милләттәшләребезнең якындан торыб катнашулары аркасында гына яхшы нәтиҗәләргә ирешәҗәкбез. «Хәбәрче»не көчләндерү, аның эчтәлек ягын югары баскычка бастыруда без укыган кешеләребезнең ярдәмләренә мохтаҗбыз. Дөньяның төрле почмакларына таралган халкыбыз арасында галим ияләре һәм дә укыган милләтдәшлеребезнең саннары аз түгел. Булар арасында профессорлар, [*лакуна*] адвокатлар, язучылар, матбугат эшчеләре [*лакуна*] докторлар, инженерлар [*лакуна*] мөгалимләр һәм һөнәр ияләре күб. [*лакуна*] Ярдәм кулын сузыб [*лакуна*] (б. 5 – 4а) халкыбыз өчен бөек чыгышларга нигез салган булыр идек. «Хәбәрче» идәрәсе моңар ышана һәм алар безнең ышанычларны буш итмәсләр. «Хәбәрче»не без нәшрият сакда, аны яшәтү, көчләндерү сезнең кулдадыр.

(б. 5 – 4б) Хәзерге вакытта халкыбызны берләштерү, ана телемезне тазартуда, файдалы фикерләр таратуда һәм уңышларыбызны күрсәтеб торучы мәҗмугага ярдәмгә килүдән милләтдәшләребез баш тартмаслар диб ышаныб теләктә калабыз,

«Хәбәрче» идарәсе.

* * *

**Болгар ханлыгы**

Болгарлар – тарихта зур роль уйнаган түрек халыкларның бересе: үз заманына күрә яхшы ойыштырылган дәүләткә, югары дәрәҗәдә торган (б. 3а) сәүдә һәм сәнәгатькә, төзү техникасына ия булган. Ислам динен беренче мәртәбә Идел буена китереб, анда мәдәният та-

раткан халык. Болгарлар беренче мәртәбә тарихта Гыйсадан суң 5 нче йөзнең азагында телгә алыналар. Ул заманда алар Кара диңгезнең төн ягындагы сәхрәләрдә Дунай, Днестр, Дон елгалары тамагында яшәгәнләр. Андан элек булгарлар хакында ишетелмәвенең сәбәбе – алар башка төрки халклары (Кутугур, Утугур, Анагур кебекләр) арасында буталыб, башка исем белән йөретелүләре булырга кирәк.

660 – 670 нчы еллар арасында болгарларның башлыгы Кубрат-хан үлгәч, аның 5 углы халыкыны бишкә бүлеб, төрле якка таралган. Аларның икесе хәзерге Мажарстан яшәгән җирләргә күчкән. Берсе (Аспарух) Дунай елгасының уң ягына чыгыб, анда хәзерге Болгарстан дәүләтен төзгән. Аларның иң зурысы Батбай гына иске җирдә калган. Батбай болгарлары соңгы вакытларга кадәре анда (б. 3б) яшәб, кара болгарлар исемендә йөртелделәр. Аларның калдыклары хәзер балкар диб аталалар.

Кубрат ханның икенче углы үзенә тигән халык белән төн ягына таба күчеб, Идел белән Кама кушылган җирләргә барыб утырган. Тарихта алар Идел яки Кама болгарлары диб исемләнәләр.

Кубрат-хан балалары әлбәтдә ирекле көндән иске урынларын ташлаб китмәгәнләр. Алар үзләренең көнчыгыш ягында яшәгән күрешеләре шулай ук төрки халкы булган хәзәрләрнең кысуына чыдый алмыйча, таралыб, яңа җирләр эзләргә мәҗбур булганлар.

Идел буенда болгарлар тормыш өчен бик уңайлы урынга туры килгәнләр. Иделнең югары агымы аркылы алар Көнбатыш Яурупа белән, аның түбәндәге агымы аркылы бөек мәдәниятле Шәрык илләре белән, Кама елгасы аркылы Урал һәм Себер белән бәйләнешдә булганлар.

Бу өлкәдә табигать байлыгы зур (б. 4а) булу сәбәбле, аларның хуҗалыгы тиз күтәрелгән, алга киткән. Аларның дәүләте зурайган һәм ныгыган. Андагы уңышлы туфрак игенчелекнең алга китүенә, куе үләнләр, киң тугайлар, малчылык үсүенә, җәнлеккә бай булган зур урманлар сунар, җиләккә, балыклы елгалар балыкчылык белән каралыныррлар, өйләр, мөселман диненә кергәч, мәчетләр салу өчен файдаланганлар.

Болгар халкының бер өлеше ауылларда, икенчесе шәһәрләрдә яшәгән. Анда заманына күрә гадәтдән тыш күб шәһәрләр булган. Ауыл халкы игенчелек, малчылык, балыкчылык, умартачылык һәм сунар белән дөнья көткән. Шәһәр халкы сәүдә һәм һөнәрчелек белән яшәгән. Болгарларда игенчелек эше яхшы тәрәккый иткән булыб, алар җир эшләү өчен хайван көче белән файдаланганлар. Аларда тимер сабан да булган.

(б. 4б) X һәм X1 йөзләрдә болгарлар күрешеләре булган Сузал [Суздаль?] урысларына аларда ачлык булган елларда иген биргәнләр.

Болгарстанда бигрәк тә сәүдә эше зур урын тоткан. Алар, бер якдан, күршеләре руслар һәм финлар белән, икенче якдан, Урта Азия, Иран, Әфганстан һәм башка Шәрык илләре белән сәүдә алыб барганлар.

Болгарлар, ясалган күн, җәннек тиреләре, бал-балауз, тере балык, балык җилеме, урман чикләүеге, сарык, мөгезле хайван хәтта сунар итләре чит илләргә чыгарыб сатканлар.

Илдә табигать байлыгының күб булуы һәм сәүдәнең киң җәелүе анда һөнәрчелек үсүенә сәбәб булган. Болгарлар Урал тавындан табылган алтын һәм көмешдән балдак – йөзек, беләзек, алка, чулпы кебек нәрсәләр ясаганлар. Алар шулай ук агач сауытлар, кашык, матур бизәкле чулпылар, төрле тимер әйберләре һәм сугыш кораллары – ук, калчуга (с. 5а) кебек нәрсәләр ясаганлар.

Болгарларда төзү эше бик алга киткән булган. Илнең баш каласы Болгар шәһәрендә ташдан салынган яхшы сарайлар, күб манаралы мәчетләр, чишмәләрендән су китерә торган балчыкдан ясалган су юллары, өйләрдә үзәклештерелгән ягу урынлары һәм балчыкдан ясалган җылы тарату юллары да булган. Болгар шәһәре Татарстанда хәзерге Эспас районында булган. Аның җимерекләре хәзер дә анда яталар һәм канәгәтленерлек дәрәҗәдә тикшерелгәнләре юк әле. Болгарларда яхшы төзү осталары булганлыгы шундан күренә. Алар рус князьләренең чакыруы буенча барыб, аларга сарайлар һәм чиркәүләр салыб биргәнләр.

Идел буенларында болгарлар килгән вакытда хәзерге мари, ар, мукшаларның бабалары булган финлар (бүген фин-угорлар термины кулланыла, ә *финлар* атамасы Финляндия халкын аңлата. – *Я.Я*) яшәгән. Алар аз-маз иген игеб, ау аулаб дөнья көткәнләр. Җир казыб яткан өйләрдә торганлар. Бу халыклар болгар дәүләтенә кереб, аңа хираж түләб торганлар. Ләкин үз башлыклары тарафыннан идарә иткәнләр. (б. 5б) Аларның хуҗалыклары күтәрелүгә, мәдәниятләре үсүенә болгарларның тәэсире зур булган.

Болгарлар 922 нче елда Алмас-хан заманында ислам дине кабул иткәнләр. Гарәб галиме Ибн Фадлан (Ibn Fadlan)дан калган хәбәрләргә караганда, 921 нче елда болгар ханы Алмас халиф Муктадирга ислам дине өйрәтүчеләр җибәрүне сораб мөрәҗәгать иткән. Халиф Муктадир 922 нче елда болгарларга алар сораган дин галимләрен җибәргән. Алар арасында Ибн Фадлан да булыб, ул болгар илендә күргән-ишеткәнләрен язып барган. Анда калган язулар безгә борынгы болгарлар хакында кыйммәтле мәгълүматлар бирә.

Ул заманда көньягында яшәгән яһүд динендә булган хәзәрләр белән көнбатышда яшәгән динсез (ул вакытда әле христиан диненә кермәгән) руслар арасында торган болгарларның ислам динен кабул итүләре, аларның ислам дөньясы белән нык бәйләнешдә булуларын күрсәтә.

(б. 6а) Чыннан да болгарлар мөселман илләре белән сәүдә бәйләнешдә генә булмыйча, сәнәгатькә, төзү эшенә ул илләрдән өйрәнгәнләр. Һөнәрчеләр кул эшендә Шәрык илләрендән килгән мөсәттарлар – бизәкләр, формалар белән файдаланганлар.

Тарихчы Гутынбурнгы, болгар ханлыгы, ул әле ислам динен кабул итүдән күб элек, культура җәһәтендә ислам динендә булган Шәрык-

ның бергәләнәсе урынын тоткан, диб яза. Ул заманда ислам культурасы иң бөек культура булуын исдә тотсак, болгарларның югары культуралы бер халык булуын күз алдына китерү ауыр түгел. Гарәб язуын кабул итү нәтиҗәсендә болгарлар арасында укый-яза белү таралган. Шәһәрләрдә һәм ауылларда мәчетләр янында мәктәбләр булган. Болгар галимләре гарәб хәрефләре илән тарих – медицина китаблары язганлар. Алар арасында йолдызлар тикшерүче астрономлар да булган.

(б. 6б) Болгар халкы гасырлар буенча тыныч һәм бәхетле яшәгән. Иленең чәчәк аткан вакыты X–XI йөзләр тирәсендә булган. Ул чорларда болгар җирләре төн ягындан Каманың урта агымына кадәре, көнбатышда Ака һәм Сура елгаларына, көнчыгышда Урал таулары һәм Җаик (Урал) елгасына, көн ягындан – хәзерге Куйбышев (Самара) шәһәре утырган урынларга кадәр җәелгән булган.

Ул вакытларда аларның көньяк күршеләре, заманында куәтле дәүләт булган хәзәрләр дәүләте инде җимерелгән. Болгарлар иске заманларда сугышчан атлы халык булсалар да, Идел буена күчкәндән соң, бара-бара сугышчанлыкларын югалтыб, тыныч бер халыкка әйләнгәнләр һәм үзләренә каршы килгән һөҗүмдән саклану, яки сәүдә юлларын юлбасарлардан саклау өчен генә сирәк-сарак сугышканлар. Күб йөз еллар буена, Себердән татар-мангуллар килеб чыкканча, алар шулай яшәб килгәнләр.

(Т. Дәүләтшин).

Бу автор турында «Габдулла Тукай. Энциклопедия» хезмәтендә түбәндәге мәгълүмат бирелә: Тимербәк Динмөхәммәт улы (1904–1983), тарихчы галим, публицист, татар эмиграциясенең күренекле җәмәгать эшлеклесе. «Салкын сугыш»чорында язылган «Совет Татарстаны»исемле китабында Татарстандагы сәясәт, мәгърифәт, мәдәният, татар халкының яшәү перспективасына бәйле мәсьәләләрне яктырткanda, Тукайны берничә мәртәбә искә ала: шагыйрьнең С. Бакырганига хас шигъри алымнарны файдалануын; М. Гафуриның, Тукайга ияреп, шигырьләрен икеюллыклар белән язуын; Һ. Такташ иҗатына Тукай йогынтысын; 1958 елда Казанда Тукайга һәйкәл куелуны; Тукай әсәрләре җыентыкларында аңа карамаган мәкаләләр барлыгын һ.б. яза. К. Насыйри, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан һ.б. белән беррәттән, Тукайны да татар халкының рус халкы белән «кушылып китү» тарафдары иде дип саный, шагыйрьнең тормыш юлына һәм иҗатына кыскача анализ бирә. М. Абдуллин һәм С. Батыев китабында бу хезмәт замана рухында тәнкыйть утына тотыла. Әсәр: Давлетшин Т. // Советский Татарстан. Казан, 2005. С. 485. Р.Р. Мусабекова [Габдулла Тукай. Энциклопедия, 2016, б. 228].

(б. 7а) **Язмыш**

Бүген рамазан бәйрәме. Быел рамазан бәйрәме елның уртасында. Көнләрнең иң озын вакытында туры килде. Бүген Истукхульм шәһәрендә кояш сәгать 2–3 дә чыгыб, сәгать 21.05 дә бата. Көн озынлыгы 19 сәгать дә 10 минут. Рамазан бәйрәмен укыр өчен Истукхульм шәһәренең иң соңгы ысулы белән эшләнгән милләт-мәдәният йортындан зур урын алынды.

Мин бина янына килеб җиткәндә, Пакистан илчесенең Пакистан байрагы илән бизәлгән автамабиле килеб туктады. Андан милли киемләргә киенгән илче һәм аның ярдәмчеләре чыкды. Озак үтмичә, Мисыр илчесе дә Мисыр байраклары белән бизәлгән автамабильдә үзенең ярдәмчеләре илән килеб җиттеләр. Соңра Түркия сәфарәт кешеләре һәм башкалары.

Шулай итеб, милләт-мәдәният йорты алдындагы мәйданда төрле-төрле мөселман илләренең байраклары белән (б. 7б) бизәлгән автамабильләр, йә инде аларның матурлыгы. Андан чыккан гүзәл милли халык киемләре киенгән илчеләрне карарга күб тамашычылар да җыйналган иде.

Гаит бәйрәменә килгән кунакларны каршы алыб күрешүләр башлангач, минем күзем читдәрәк утырган бер кара кешегә төшеб, «бу бер сәфарәтнең автамабиль йөртүчесе нигрмы икән» диб уйладым. Ул бөтенләй кара. Күзенең аклары белән, тигез ямьле ак тешләре генә кара тән өстендә бик ачык күренә иде. Ул таза гәүдәле, кырын рәвешдәрәк утырган. Мин аңар якынлашкач, ул утырган урыныннан күтәрелә төшеб исәнләшергә хәзерләнгәнен күргәч, якын килеб сәлам бирдем. Ул: «Галейкум ассәлям» диб сәламемне каршы алды. Кулымны кысды. Ул гәзитәләрдәге «Рамазан бәйрәме, гаид намазы укыла» дигән игъланны укыб, бу бөек бәйрәмгә килгән африкалы бер мөселман булыб, Истукхульмда бер фабрикада эшдә икәнен дә сорашыб белдем. (б. 8а) Гает фитр намазы укылгач, бер яшь укучы егет бик моңлы тауыш белән Кор’ан укыды. Бу бөек бинаның зур залы Кор’ан тауышындан калтыраб яңгыраб калды. Бу вакытда мөселманларның, илчеләрдән башлаб гадәти эшче кешеләргә кадәр, барчасының күзләрендә яшь бөртекләре күрергә мөмкин иде.

Бәйрәм намазы укылгач, тәбрикләшүләр башланды. Пакистан илчесе барча мөселманлар белән күкрәкләрне – күкрәкләргә, бер уңга, бер сулга тидереб кочаклаб тәбрикләшде. Тиздән бу гадәт барча мөселманларга ирешеб, бер-берсе белән кочакланыб битләрен битләрегә тидереб, күкрәкләргә кысыб, чын мөселманлык, саф дустлык-өзелмәслек элемтә нигезенә юл салыб, аның нинди көчле бәйләнешдә икәнен күрсәтделәр.

Бу дустлык күреб, тәндән электр көче үткән кебек сизелде. (б. 8б) Теге кара кеше дә мине – мин аны кочаклаганда, мин аның гадәтдән тыш булган йөрәк тибүләрен сизеб, анда бер зур мөселманлык хисләре, көләч йөзендә бер бөек шадлык – бәйрәм шадлыгы булуын аңладым.

Милләт-мәдәният бинасындан чыккач, көн гадәтдән тыш җылы, матур булганга, бераз йөреб барырга уйладык. Кара кешем бездән бераз алдарак, кулына бер китаб тоткан, кибетләрнең тәрәзәләрендән карый-карый бара иде. Мин аны күргәч, йөрүне тизләштереб, артындан җитәм дә бәйрәм чәен эчәргә өйгә чакырыйм диб ният итдем. Ләкин ул урамның икенче ягына чыгыб тар бер урамга кереб күздән

югалды. «Әллә мескен үзенең кара булуына ояламы? Тагы мин аны очрата аламынмы икән?» – дигән фикерләргә чумдым.

(б. 9а) Мин аны артык очрата алмадым. Ул эшләгән җирдә патроль миче шартлаб, аны каты рәвшендә яндырыб, хастаханәдә кызганычлы үлем белән вафат булган.

Аның соңгы сүзләре: «Мине мөселманлар үз каберлекләренә күмсенләр, пакьләсенләр, йөземне кыйбла тарафына куйсынлар, кәфенләсенләр һәм Кор'ән укытсынлар», – дигән. Аның якын танышлары Исвичлылар бу сүзләрне Исвичдагы дини-мәдәни-түрек-ислам оешмасына җитештерделәр. Аның соңгы теләкләрен үтәр өчен, мондан берничә сәнә әүвәл алынган оешманың каберләренә күмәргә булыб, карт кешеләребезнең җитәкчелеге белән күб кешеләр пакьләүдә катнашырга булган теләкләрен белдерделәр. Хатынлары кәфенлекләрене хәзерләделәр. Истукхульмдагы барча мөселманлар аны соңгы юлга озатырга каберләргә җыйналдылар.

Җиназа намазы укылды. Мөселманлар үз куллары белән мәетне кабергә төшерделәр. Күмү сүзе сөйләнде. Кор'ан укылды. Шулай итеб, эссе Африканың уртасындан (б. 9б) булган бер мөселман Кыяи Мамаду Истукхульм ислам каберендә беренче мәет уларак урын алды.

Кем уйлаган эссе Африкадан салкын шимальда гүргә керүне. Бер Ходайдан башка инсанларга мөмкин түгел аны белүне. Без белмибез: кайда? кемләр? безне шулай гүргә куярлар? Гөлләр кебек безнең каберне дә матур чәчәкләргә буярлар. Язмышларны алмаштырыб булмый, буйсынабыз сиңа, Ходабыз. Иман белән үткәр бу колыңны, сораб Раббыма дога кылабыз.

(Абу Бәкир)

Рәхмәт. Төрек-ислам оешмасына һәм барча әгъзаларына Кыяи Мамадуны күмүгә якындан торыб катнашучыларга һәм чәчәкләр күндергәнләргә бөек рәхмәт укыйм.

(Бита Юнсон)

(б. 10) **Төрек углы**
Иренмәс ул, [...] чабса карамый картка һәм яшькә,
Түләр бурчын, сөйләр тугры, түзәр михнәткә, хәсрәткә.

Тотар алда халык бәхетен. Атар җаныны төреклеккә,
Сөяр дин һәм гадәт-горефен. Аны хет тот та үтер дә.

Җылынган ул – бу үсмердә мөселман каны җан – тәндә:
Йә инде бармы монда зур, бәхетле башка бер бәндә?
(Хәсән Хәмидулла)

**Ататүрк**

(а) Тарих битләрендә аз очратам
Синең кебек даһи кешеләрне,

Милләтеңне утдан чыгарыр өчен,
Эшләдең син бөек эшләрне.

(б) Тайфун җилләредәй себерев түктең
Дошманларның кара көчләрен,
Күтәрелде барлык төрек халкы
Эшләр өчен бөек эшләрен.

(б. 11а)
Яшен кебек синең гаскәрләрең
Һич курыкмасдан алга атлады,
Тар-мар итеб дошман гаскәрләрен,
Байракларын җирдә табтады.

Рәсемеңгә караб хайран калам,
Сократларга тиңним үзеңне,
Аерыб торды сездән кара дивар, шуның өчен
Барыб күрә алмадым үзеңне.

Менә хәзер рәсемеңә караб,
Җыр җырлыймын синең турыңда,
Илебездә кордың күб гигантлар
Гөрләб торды синең кулыңда.

Бакчаларың матур чәчәкләр ата,
Йөзем – җимешләрен бирмиләр,
Ерак почмаклардан күб галимләр
Күрер өчен илеңә килделәр.

(б. 11б)
Шәрык дәүләтләре арасында
Якты йолдыз булыб тордың син,
Артта калган Төрек хөкүмәтен
Яңа баштан алыб кордың син.

Бәхетсездән булдым, Кемаль Ата
Истина алмадым кайнар сүзеңне,
Әгәр исән булсаң, Кемаль Ата,
Кочыб йыглар идем үзеңне.

Күпме генә сагыныб йыгласам да
Күрә алмыймын нурлы йөзеңне,
Төнләр буе, Ата, уйлаб ятам
Күз алдыма китереб үзеңне.
(Минһаҗ)

(б. 12) **Әнкәй**
(а) Әнкәй бәгърем, мине тудырганда, нинди уйлар булды башыңда?
Ахырысы гөнаһ эшләгәнмен, газаб чигәм Алла каршында.
Аердылар туган илемдән дә, бала чагымны да ташладым,

Килемшәкдәй йөреб чит илләрдә, авыр тормыш итә башладым.
Нигә ташладың син бу диңгезгә – «дулкын басыб үлсен!» дидеңме?
«Бәхетле булсын, минем балам!» диеб, хәер-дога кылыб йөрдеңме?
Беләм, әнкәй бәгърем, минем өчен – ут эченә хәтта керә идең,
Бер кабарлык ризык булмаса да, әллә кайдан табыб бирә идең.
Онытмамын, әнкәй, һич вакытда, сагыныб – сагыныб сине сөярмен,
Искә алыб сине, әнкәй бәгрем, эчләремдән яныб киярмен.
(б) Һич онытмам йомшак кочагыңны, онытмам татлы сүзеңне,
Төнләр буе, әнкәй, уйлаб ятам, күз алдыма китереб үзеңне.
Күкрәк сөтең миңа имездең, кеше итәргә иде теләгең,
Төнләр-көнләр бишек тирбәткәндә, арыб бетә иде беләгең.
Искә алсам, әнкәй, хушсыз калам, безне ташлаб киткән көнләрне,
Әткәй белән сине күмеб кайткач, үткәрдек без моңсу төнләрне.
Күккә бактым астрономлар сыман, таба алмадым синең йолдызны,
Йөзеб китде җиһан дәрьясына, тота алмадым кулда кондызны.
Караңгы төнләрдә синең йолдыз, йул күрсәтә иде безләргә,
Бик сагындым, әнкәй, беләсеңме, кай җирләрдән сине эзләргә?
(Минһаж)

(б. 13) **Байрак тартышы**

Шаулый дөнйа һәммә җирдә. Киң җиһан җитми, тыгыз,
Юк тынычлык кайда барсаң да – бүленгән тиб-тигез.
Инде һәр милләт рәхәтсез, орыша төрле партиялар,
Ак, кара, күк һәм кызыл «чүпрәкне» бар да парчалар.
Алла урнында хәзер чүпрәк. Бөгә баш барсы да,
Баш ялангач табына шул чүпрәккә – бай-ярлысы да.
Күнмиләр һәм килмиләр һичбер фикергә падшалар,
Җитми җир, мескенне бар да – өзгәләр дә тарткалар.
Юк тынычлык айга да: инде бүләләр айны да,
Бу атумлар һәм ракитлар – айга бәрми калмый да.

Кайда бакма җир казылган, тауларын һәм ташларын,
Алган инсан, чүпләгән – алтын, күмер һәм газларын.

Җир казылган төбкәчә – алса да инсан байлыгын,
Ярлы ул мәңге! имә аның сугыш ни барлыгын.
(Хәсән Хәмидулла)

(б.14) **Изге Мәккә шәһәре электрлаштырыла**

(а) Ислам дөньясының изге шәһәре булган Мәккә кыска вакыт эчендә электрлаштырылачак. Мәккәдән тыш инглиз инженерлары бер электр көче бирә торган бина төзеб, шундан бирелгән электр белән Мәккә шәһәренең урамлары һәм йортлары яктыртылачак. (б) Мәккә шәһәре эчендә бу эшләрне мөселманлар үзләре башкарачаклар. Ислам динендә булмаган чит кешеләрне шәһәргә йибәрмәс өчен, электр бинасы да шәһәрдән бер яктарак салыначак.

«Моргон тиднинг» (МТ)

**Ибраһим Гомәркәйгә 75 яшь**

Бу 1952 нче сәнә, 15 нче октябрьдә Ибраһим Гомәркәй әфәндегә 75 яшь тулды. Дини-мәдәни-төрек-ислам оешмасы һөм аның каршында чыга торган «Хәбәрче» мәҗмугасы аның бу бәйрәмен тәбрик итеб, аңа тагы озын гомерләр теләб калалар.

(б. 15)

(б. 16–19) **Яңа Хуҗа**

Яңа Хуҗа бер кичне өйенә кайтырга соңга калган. Ул трамвайлар туктала торган урынга баскан, бик озак вакытдан бирле трамвай көтеб тора башлаган. Шәһәр урамында һич бер кеше юк, биек йорт башындагы сәгать 3 туларга күб калмаганны күрсәтә. Әллә кайдан бер кеше чыгыб, Хуҗага: Агай! Сәгать 3 тула инде, бу вакыт трамвайлар йөрмиләр, сез аны юкка гына көтәсез, дигән. Хуҗа: Трамвайлары йөрмәсә , нигә соң тимер юлын алмаганлар, диб җаваб кайтарган да һәм тагы көтә биргән.

Бер кичне Яңа Хуҗа бик соңга калыб өйгә кайткан. Йортының икенче катындагы йокы бүлмәсенә менәргә кирәк булган. Ул хатыны уяныб, соң кайткан өчен орышмасын- шелтәләмәсен, диб, аяк киемләрен салыб – акрын генә баскычларга басыб менә башлый. Шул ук вакыт бөтен тауышы белән, «Мөхәммәдия»дән: «Чын адәм җәннәтә улды» диб көйләб менә башлаган.

Хөрмәтле укучы! Укы Хуҗаны – ләкин Хуҗа булма!

(б. 18–15а, б**) Беләсезме?**

Бер 70 яшлек урта Кот-бот-дин агай үзенең гомерен, чама белән алганда, шулай бүлә:

йоклау …......24 сәнә<br>
эш…………....14<br>
буш……..........8<br>
аш……….........6<br>
йөрү- йуллар...5<br>
сөйләшү…......4<br>
уку……….......3<br>
һөнәр өйрәнү..3<br>
һәм башкалар..3<br>
70

Һәрбер хатын-кыз уртача бер сәнәдә 30 сәгать көзге каршында вакыт үткәрә.

(С.М.)

(б. 20–17) **Почта көтәсе**

«Хәбәрче» мәҗмугасының идарәсенә төрле җирләрдән туктаусыз хатлар килеб тора. Бу хатларның барчасына кечкенә мәҗмугабызда

урын бирү мөмкин түгел. Шулай булса да, килгән хатларның кайберләрендән өземтәләрне күрсәтеб үтүне тиешле табдык.

(а) Соңгы хатыгыз һәм анда язылган мәгълүматләр өчен сезгә рәхмәт. Журналыгызның планы миңа бик ошады, бигрәк дә сәясәткә кушылмавыгыз һәм башкаларны хурлаудан читтә булырга тырышуыгыз күңлемә бик тугры килде.

(Профессор Т. Дәүләтшин)

(б) Сезнең шушындай бөек бер эшкә күңел баглавыңыз һәм карарыңыздан бик мәмнүн булдым. Сәбәбинәгез шәб, тырышыб карасагыз афарин укырлык бер эш ябмамыш улурсыңыз.

(Матбугат эшчебез: Хәсән Хамидулла)

(б. 21–18а) Сезнең «Хәбәрче» исемле ана телендә чыгарырга уйлаган журналыгызга Алла ярдәм бирсә, без, мин генә түгел, милләтен сөйгән бөтен мөселманлар читтә качыб калмастан катнашыб, кирәкле ярдәмләрен бирерләр дип ышанам. Алла ярдәмен биреб, уйлаган эшеңезне гамәлгә ашырсаңыз бик яхшы булыр иде.

(Шагыйрь Минһаҗ)

«Хәбәрче» исемендә бер мәҗмуга чыгарыр хәбәрене укып күб сөендек. Алла муафикъ әйләсен. Амин. Беренче номеры чыккан булса, күндерүне үтенәм. Әгәр дә мәҗмугаңыз чыга башласа, без дә кулыбыздан килдеге кадар мәкалә язып торырбыз.

(Имам Хабиб Аррахман Шакир)

(б. 21 – 18б) Сезнең «Хәбәрче» журналы чыгаругызны ишетеб бик шатландым, һәм сезгә Алладан күб-күб уңышлыклар телим; үзебезнең ана телендә бер журнал чыгуы – безләргә зур куаныч.

(Рауф Ирнасыр)

Килгән хатларның эчтәлекләрендә барча милләттәшләрнең фикерләре бер булыб, «Хәбәрче» мәҗмугасының чыгуын ишетеб, үзләренең шадлыкларын белдереб, аңарга киләҗәктә ярдәм кулын сузарга хәзер икәнләрен сөйләб, бу башланган эштә уңышлыклар теләб калалар.

(Хәбәрче идарәсе)

(б. 22 – 19а) **Халкыбызның җырлары**

Халкыбызның көйләре һәм теле сакланыб калсын дигән ният белән яңа башлаб чыккан «Татар халык җырлары» дәфтәре идарәбезгә килеб җитде. Бу дәфтәрдә халкыбызның иң яратыб җырланган җырлары ноталарга салыныб, милли көйләр чын-дөрестлекләре сакланыб тәртибкә салынган.

Халык җырларындан иң мәшһүрләре, моңлылары бу дәфтәрдә тубланыб, әлегә кадәр төрле җирләрдә урынына җитештерелми

җырланыб килгән булса, әүвәл ничек дөрест җырланган дәрәҗәгә китерүдә күб ярдәм итәчәк.

Зур рәүштә, яхшы кәгазьгә басылган булыб, беренче тышкы битендә – Сөембикә манарасы рәсеме белән бизәлгән. Казан латин харефләре илән җырлары язылган.

(б. 22–19б) Бу дәфтәр үз эченә 23 милли җырларны алыб, алар түбәндәгедән гыйбәрәт.

| | |
|---|---|
| 1 – Эскадрун, | 12 –Урман кызы, |
| 2 – Батыр егет, | 13 – Сагыну, |
| 3 – Ашказар, | 14 – Сәлам хат, |
| 4 – Зиләйлүк, | 15 – Уракчы кыз, |
| 5 –Авыл, | 16 – Ак каен, |
| 6 – Кара урман, | 17 – Галийабану, |
| 7 –Үкенеч, | 19 – Каз канаты, |
| 8 –Тәфтиләү, | 20 – Мактанчыклар, |
| 9 – Мәхбус, | 21– Тамчы там, |
| 10 – Шам шәриф, | 22 – Әпипә, |
| 11– Таһир-Зөһрә, | 23 – Май камаль. |

Теләгән милләтдәшләр! Бу дәфтәрләрне Heberci Upplans vasby Box 82 (Sweden) адресы белән сората аласызлар.

(б. 23–20)

**Буш вакытда баш ваткычлар**

Буш вакытта. (*Кроссворд ясалган.– Я.Я*).

Сулдан уңга таба: Төрле милләтләрнең билгеләре. 4. Ирек (Тоткын түгел). 5. Рамазан аенда. 6. Имам хотба укый торган җир.

Өстән аска таба: 1. Инсанларнын бергәләп үткәрә торган шадлык көнләре. 2. Мәмнүнлек (Каршы түгел). 3. Дин китабларында эт (көчек) исме.4. Намазга чакыру.

Җавабын тугры итеп күндергән кеше бүләкләнә.

Башваткыч (*Геометрик фигуралар ясалган. – Я.Я*).

Шушы 6 кисәкне качы белән кисеп алыгыз да, шулардан йаңа түрк әлифбасының беренче хәрефен чыгарыгыз. Җавабын җибәргәндә, бер кәгазьгә йабыштырып нинди хәреф икәне күренсен.

(б. 24–21) «Хәбәрче» мәҗмугасы түбәндә күрсәтелгән бүлекләрне үз эченә ала:

1 – Мөселман оешмаларының эшләрендән белдереб, аларны көчләндерүдә булган файдалы фикерләр, киңәшләр һәм хәбәрләр.

2 – Дин мәсьәләсе, дини тәрбия.

3 – Тарих, төрек кабиләләренең тарихлары.

4 – Тәгълим-тәрбия эшләре, тел мәсьәләсе.

5 – Әдәбият, язучыларыбызның иҗадлары, иҗтимагый хәлләре, хикәяләр, шигырьләр, яшь язучыларга киң урын бирү.

6 – Хатын-кызлар һәм балалар бүлеге.

7 – Мөселман илләре хакында чыккан матбугат хәбәрләре.

8 – Сорау-җаваб бүлеге.

9 – Буш вакытда – башваткычлар.

«Хәбәрче» мәҗмугасы Исвичдәге дини-мәдәни-төрек-ислам оешмасы каршында чыга.

Чыгаручылар: редакция коллегиясе.

«Хәбәрче» мәҗмугасы түбәндә күрсәтелгәнләрне үз эченә алмый:

1 – Нинди генә рәвешдә булмасын, сәясәт эшләре.

2 – Бер-бер оешманы, йә булмаса аерым кешеләрне пычырата торган урынсыз тәнкыйть.

***Янбаева-Әхмәтгалиева Ялкын,***
*филология фәннәре кандидаты (Израиль)*